СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

02.04.2024

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

40-228

с. Нижний Услон

Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Ослан җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә Түбән Ослан авылы торак пунктының бер өлешенең халык төркеме инициативасын карап,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендә гражданнардан җыелган үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга;
«2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 4600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез ризамы:

- Карл Маркс урамындагы бистә эчендәге юлны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Түбән Ослан авылы, Карл Маркс урамы 47 нче йорт янында гражданнар җыенын 09.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын

оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В. Архиреев